| | | |
|---|---|---|
| **РАСЛЫЙМ** | **РАСЛЫЙМ** | **РАСЛЫЙМ** |
| Россия ислам институты ректоры<br>Р.М. Мөхәммәтшин | Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы Диния нәзарәте Мөфтие<br>К.И. Сәмигуллин | «Идел» журналы баш мөхәррире<br>Г.Р. Закирова |

# «Таян Аллаһка» әдәби конкурсының
# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## I. Конкурсның гомуми нигезләмәләре

**1.1**. «Таян Аллаһка» әдәби конкурсы Россия Федерациясендә яшәүче татарлар арасында талантларны барлау һәм берләштерү, аларның иҗади эшчәнлекләрен үстерү максатында уздырыла.

Конкурсның бурычлары:

– сәләтле яшьләргә, башлап язучыларга иҗади үсеш өчен шартлар булдыру;

– татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен һәм ислам динен пропагандалау.

Оештыручылар:

«Идел» журналы, Россия ислам институты, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы Диния нәзарәте.

**1.2.** Вакыты һәм үткәрү тәртибе

Конкурс өч этапта үтә:

1 этап – әсәрләрне кабул итү (1 февраль – 30 апрель 2022 ел).

2 этап – әсәрләрне жюри тарафыннан бәяләү (1 май – 30 июнь 2022 ел).

3 этап – җиңүчеләрне бүләкләү (сентябрь 2022 ел).

## II. Конкурста катнашу шартлары

**2.1.** Конкурста Россия Федерациясендә яшәүче 10 яшьтән 45 яшькә кадәрле һәрбер теләгән кеше катнаша ала.

**2.2.** Конкурс иҗат эше белән профессиональ рәвештә шөгыльләнмәүче яшьләр өчен үткәрелә, профессиональ язучыларның, шагыйрьләрнең, журналистларның әсәрләре һәм язмалары кабул ителми.

**2.3.** Конкурсның быелгы өстенлекле темасы: Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы.

**2.4.** Конкурска тәкъдим ителгән әсәрләр һәм мәкаләләр **әдәби татар телендә** язылырга тиеш.

**2.5.** Конкурс номинацияләре:

- шигърият;
- чәчмә әсәр;
- публицистик язма.

**2.6.** Аз күләмле әсәрләр (шигырьләр, кыска хикәяләр һ.б.) һәм публицистик язмаларның саны өчтән дә ким булмаска тиеш. Аларны түбәндәге таләпләргә туры китереп эшләргә кирәк: Times New Roman шрифтында, 14 нче кегль, бер ярым интервалда, сул яктан – 30 мм, уң яктан – 10 мм, өстән – 25 мм, астан – 20 мм.

**2.7.** Авторлар эшләрен өч номинациянең берсенә генә җибәрә ала, ягъни бер автор бары бер генә номинациядә катнаша ала.

**2.8.** Конкурска язмалар электрон вариантта кабул ителә. Конкурс материалларын җибәрү өчен электрон адрес: tatarkonkurs@mail.ru

**2.9.** Әсәрләр белән бергә конкурста катнашучы үзе турында кыскача мәгълүмат, адресын һәм телефон номерын җибәрергә тиеш. Конкурска җибәрелгән материалларны алып теркәгәннән соң, оештыру комитеты авторларның электрон почтасына раслау җибәрә. Конкурс белән бәйле барлык мәгълүматлар да оештыручыларның рәсми сайтларында урнаштырылачак.

## III. Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

3.1. Конкурста катнашучыларның әсәрләрен анализлау һәм бәяләү өчен оештыру комитеты тарафыннан махсус комиссия (жюри) билгеләнә.

3.2. Комиссия, конкурска килгән язмаларны тикшереп, һәр номинациядә беренче, икенче, өченче урыннарны билгели. Моннан тыш, Гран-при, махсус бүләкләр булуы да мөмкин.

Жюри Гран-при һәм призлы урыннарны бирмәү хокукына да ия.

Конкурс нәтиҗәләре буенча лаеклы дип табылган әсәрләр «Идел» журналы битләрендә урын алачак.

Оештыру комитеты адресы: Казан ш., Газовая урамы, 19 нчы йорт. Татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы. E-mail: tatarkonkurs@mail.ru

Белешмәләр өчен телефон: 8(843)2776826.